ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 2 һәм 45 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктчасында «Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасының башка законнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлегенә өлешле гомуми милек хокукында өлешләрнең гектарларда яисә балло-гектарларда белдерелгән күләмнәрен гади ялгыз вакланма рәвешендә билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында карар.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 февраль
№ 4-ТРЗ